**Камаева Рима Биҗановна,**
***филология фәннәре докторы***
***Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты***
***татар филологиясе кафедрасы профессоры***
***Усманова София Алимовна,***
***филология фәннәре кандидаты (PhD),***
***Коканд дәүләт педагогика институты***
***узбәк теле кафедрасының өлкән укытучысы***

# ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ КОМПОНЕНТЫ БУЛАРАК СИМВОЛЛАР

**Аннотация.** В данной статье рассматриваются концепты-символы в компонентах фразеологических единиц, извлеченных из произведений современных татарских прозаиков Н.Фәттаха, М. Хәбибуллина, Р.Батуллы, Т.Галиуллина, В. Имамова, Ф. Сафина. Воплощение определенных образов, связанных с внутренним миром своих героев, авторы связывают с фразеологизмами, которые имеют концептов-символов *җан, күңел, бәгырь, (душа*), *йөрәк* (сердце).

**Ключевые слова.** татарские прозаики, фразеологизм, концепт-символ.

**Annotation.** This article examines the concepts-symbols in the components of phraseological units extracted from the works of modern Tatar prose writers N.Fattakh, M. Khabibullin, R.Batulla, T. Galiullin, V. Imamov, F. Safin. The authors associate the embodiment of certain images associated with the inner world of their heroes with phraseological units that have concepts-symbols җan, kunel, bagyr, (soul), yorak (heart).

**Key words:** Tatar prose writers, phraseology, concept symbol

**Аннотация.** Бу мәкаләдә хәзерге татар прозаиклары Н.Фәттах, М.Хәбибуллин, Р. Батулла, Т.Галиуллин, В.Имамов, Ф.Сафин әсәрләреннән алынган компонентларында концепт-символлар булган фразеологик берәмлекләр тикшерелә. Үз геройларының эчке дөньясы белән бәйле билгеле образларны авторлар фразеологизмнар белән бәйлиләр, алар арасында җан, күңел, бәгырь, йөрәк концепт-символлары бар.

**Төп сүзләр:** татар прозаиклары, фразеологизм, концепт-символ.

**Annotatsiya.** Ushbu maqolada komponentlari zamonaviy Tatar Nasr yozuvchilari N. Fattax, M. Xabibullin, R. Batulla, T. Galiullin, V. Imamov, F. Safin asarlaridan olingan konseptual ramzlar bo'lgan frazeologik birliklar muhokama qilinadi. Mualliflar o'z belgilarining ichki dunyosi bilan bog'liq bo'lgan ba'zi tasvirlarni frazeologik birliklar bilan bog'lashadi, ular orasida ruh, ruh, qayg'u, yurak tushunchalari mavjud.

**Kalit so'zlar:** Tatar Nasr yozuvchilari, frazeologiya, tushuncha ramzi.

Фразеологик материал символларны күзәтү өчен киң мөмкинлек бирә, чөнки аларның тотрыклылыгы, кабатлана алуы, милли үзенчәлеге символик мәгънәне ныгыту өчен шартлар тудыра, символның милли-тел үзенчәлекләрен ачыклауга ярдәм итә.

Ю.А. Гвоздарев фразеологизмнар составында сүз-символларны тикшерүнең мөһимлеген билгели. Ул телдәге символларның «халык рухын, аның тарихи тамырларын» ачыклавын ассызыклый. "Төрле телләрнең

фразеологиясендә сүз-символларны чагыштыру телләрнең милли үзенчәлеген ачарга һәм уртак урыннарны ачыкларга ярдәм итәчәк» дип билгели. [Гвоздарев1981: 120].

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, әдәби әсәрләрдә фразеологик берәмлекләр автор сөйләмен һәм геройларны сурәтләү өчен нәтиҗәле образлы чараларның берсе булып тора. Күренекле татар прозаиклары Н.Фәттах, М. Хәбибуллин, Р.Батулла, Т. Галиуллин, В. Имамов, Ф. Сафин үзләренең әсәрләрендә кешенең эчке дөньясын, физик халәтен, аның эш-гамәлләрен тасвирлау максатыннан компонентларында символлар булган фразеологизмнарны киң кулланалар. Компонентында *җан, күңел* лексемасы булган фразеологизмнарны карап үтик.

*Җан бирү* (В.Имамов), *җаны күккә ашу җаны җәннәткә китү* (М.Хабибуллин); *җан тәслим кылу* ,җан тарту (Р.Батулла) –*җан иңү, җан керү* (В.Имамов).

«Ул *җан биргәнне* ишеткәч кенә чышан-пышан килеп хәбәр кузгаттылар» [В.И. «К.д.», 2005: 17]. «Көтмәгәндә такыяга *җан иңгән*, ди» [В.И. «К.д.», 2005: 23]. «Фани дөньядан китәр алдыннан соңгы оныгын күрмәенчә ул *җан тартмас*» [Р.Б. «С.», 1992: 59]. «Шулай итеп угыл оланга *җан иңде*» [Р.Б. «С.», 1992: 95].

Кайбер очракларда авторлар *җан* лексемасы булган фразеологизмнарны кешене уңай яки тискәре яктан тасвирлау өчен файдаланалар: *җан дус, җан ахирәте* – якын кеше, дус; *җан кисәгем* – якын кешегә иркәләп эндәшү өчен кулланыла; *җан көеге, җан имгәге* – һәрвакыт кайгы гына китерүче кеше.

«Булачак *җан ахирәте,* соңрак кан дошманы Надия белән институтка керү имтиханнарын биреп йөргәндә таныштты» [Т.Г. «Т.ю.», 2005: 494]. «Юк, юк, *җан кисәгем,* мин илле, йөз елдан соң оҗмах кошы булырсың димәкче идем» [Т.Г. «Т.ю.», 2005: 548]. «Әлбәттә, ул аларның – ата-аналары өчен *җан көекләренең* – тулы гаепләрен, шөгыльләрен белми иде» [Т.Г. «Т.ю.», 2005: 514].

Язучылар аеруча актив рәвештә *җан* лексемасы белән фразеологизмнарны үз геройларының эчке дөньясын, эмоциональ халәтен тасвирлау өчен кулланалар. Һәр автор кеше күңелендә булган кичерешләрне, җан сызлавын, дулкынлануны, борчылуны, кайгыны, сагынуны үзенчә тасвирлый.

*Җан-фәрманга кычкыру*, *җан яраларын ачу*, *җанны талау, җанны тетрәтү*, *җанны тырнау*, *җанына савылган моңсулык, җанын тырнаган билгесез борчу*, *җаны-тәне белән гашыйк булу җанны явыз мәчеләр тырнау, җанга яшендәй үтеп керү* (Т.Галиуллин “Төнге юллар”).

« – Болай да *җанымны явыз мәчеләр тырный*» [Т.Г. «Т.ю.», 2005: 549]. « – Шуның өстенә мин сиңа *җаным-тәнем белән гашыйк булдым*» [Т.Г. «Т.ю.», 2005: 562].« – Дөресен әйтәм, Әнисә, син рухыма, *җаныма яшендәй үтеп кердең*» [Т.Г. «Т.ю.», 2005: 550]. « – *Җан яраларыңны ачма!* [Т.Г. «Т.ю.», 2005: 492]. «Билгесез сагыш, әллә каян җанына савылган моңсулык, эчке сыкрану борчып тора» [Т.Г. «Т.ю.», 2005: 549].

Җан авазы, җанын җылытырлык сүз, җан ачысы, җан сыкрау җан бәргәләнү (В.Имамов “Казан дастаны).

*Җаны-коты үкчәсенә җитү*, *җанга тию*, *җаны актарылу*, *җан кыйналу*, *җан ачысы*, *җанын биләү*, *җанын көйдерү*, (М.Хабибуллин”Кубрат хан”). *Җан ачысы*, *җанны актару җан асрау*, *җанына ачкыч ярату*, ***җаннары берегеп***

*җитмәү, җанына кагылып китү, җанында яралу* (Ф.Сафин «Саташып аткан таң»)

«Сәйдәш уйнаган музыка *җанны актара*» [Ф.С. «С.а.т.», 2003: 156]. «Әллә Мостафа белән ***җаннары берегеп*** *җитмәгәнне аңлап*, шушы сәбәп белән араны өзү, өйдән чыгып китү җаен карыймы?» [Ф.С. «С.а.т.», 2003: 99]

Фразеологизмнар составында *күңел* концепт-символы шулай кешенең хисләре, кичерешләре, җан газаплары, шатлык чыганагы булып тора: *күңел бөрешеп калу, күңел тырналу, күңелне корт кимерү, күңел кырылу, күңел тетрәнү,күңел бушап калу, күңел нечкәрү, күңел куаныч белән тулу* (Н.Фаттах); *күңелгә кара сөрем утыру, күңеле авыр кичерү, китек күңел, күңел тулу, күңеленә шом төшү, күңелен әсәрләндереп җибәрү* (Т.Галиуллин), *күңеле борчылу, күңелдә соңгы өмет сүнү, күңел офыклары киңәю* (Р.Батулла), *күңеленә юл таба алмау* (Ф.Сафин).

«Эч пошу, *күңел тырналу* исә аның күзгә күренмәгән әлеге чирен генә көчәйтте» [Н.Ф. «Ител», 1980: 12]. «Тотыш! – диде Торымтай, *күңеле тулып*» [Н.Ф. «Ител...», 1980: 223]. « – *Күңелемне бер уй тырный,* Тотыш...» [Н.Ф. «Ител...», 1980: 267]. «*Китек күңел* ниләр генә барлап бетерми» [Т.Г.«Т.ю.», 2005: 520]. «Таҗдар *күңелендә шом кузгалды*» [В.И. «К.д.», 2005: 15]. «Акмирза-Сөем тутайның *күңеле борчыла башлады*» [Р.Б. «С.», 1992: 15]. «*Күңеленә шом төшкән* Әлфия, кабалана-кабалана, төсле клеенканы күтәрде» [Т.Г. «Т.ю.», 2005: 607]. «Үзеннән куркуларына *күңеле булып,* эре генә баруында булды» [Н.Ф. «Ител...», 1980: 9] «Акбүреләрнең *күңелләре куаныч белән тулды*» [Н.Ф. «Ител...», 1980: 39] «Яшь җегетнең *күңеле эреде дә куйды,* аны *татлы кайнар дулкын күмеп китте*» [Н.Ф. «Ител», 1980: 146] «*Күңел каядыр ашкына*, каядыр *омтыла,* кемдер дәшә, чакыра сыман!» [М.Х. «К.х.», 1985: 130]. «Ә монда, сарай урамы чатында тыңлаган җыр аның *күңелен айкап ташлады*» [М.Х. «К.х.», 1985: 123] «Оркестр уйнаганда *күңел офыклары киңәеп китте,* уй-хисләр тагын да җанлырак, нурлырак, сыман тоелды» [Ф.С. «С.а.т.», 2003: 116]. / «Аз-маз керем күренә башлагач, егетләрнең *күңелләре күтәрелде*, эш алга китте» [Ф.С. «С.а.т.», 2003: 124]. «Габдулла хан *күңеленең һәр почмагы түм-түгәрәк иде*, һәммәсен дә елмаеп кына күздән кичереп утырды» [В.И. «К.д.», 2005: 8].

Шулай итеп, күп санлы мисаллар күрсәткәнчә, язучылар үз әсәрләрендә компонентында концепт-символлар булган фразеологизмнарны актив кулланалар. Концепларның символик әһәмияте тел үзенчәлеген, фразеологик кушылманың милли үзенчәлеген күрсәтә, халык тарихы белән бәйләнешен аңларга ярдәм итә.

Әдәбият


1. Батулла Р. Сөембикә: Кыйсса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 415 б.
2. Галиуллин, Т.Н. Сәет Сакманов: Роман-трилогия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 656 б.
3. Гвоздарев Ю.А. Сопоставительное описание фразеологии разных языков // Образование и функционирование фразеологических единиц: Сб. ст. / Отв. ред. Ю.А. Гвоздарев. – Ростов н/Д., 1981. – С. 116-121.
4. Имамов В.Ш. Казан дастаны: Тарихи роман /В.Ш. Имамов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 239 б.
5. Камаева Р.Б. Национально-специфический корпус татарской лексики в

современной прозе: лингвостилистические характеристики и способы перевода на русский язык// Казань: Редакционно-издательский центр "Школа", 2019. – 268 с.

6. Сафин Ф.М. Саташып аткан таң: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 726 б.
7. Сафиуллина, Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.
8. Фәттахов Н.С. Ител суы ака торур. Тарихи роман. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. – 398 б.
9. Хәбибуллин М.М. Кубрат хан: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 376 б.
10. Хәбибуллин М.М. Шайтан каласы. Тарихи роман . – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 303 б.

***Hasanova Dilfuza Odilovna***
***Qo'qon DPI dotsenti, filologiya fanlari doktori***

## SHAXSNI JINS JIHATDAN IFODALOVCHI LEKSIK BIRLIKLARNING IZOHLI LUG'ATDA BERILISHI

**Annotatsiya.** Ushbu maqolada leksik birliklarning barchasida shaxsni jins jihatidan ifodalash ma'nosi yetakchi mavqeni egallab turganligi, shaxsning ijtimoiy holat va munosabatlari turli omillar chambarchas bog'liqligi, bu holat shaxsning sotsial belgilarini ifodalovchi leksik birliklar lisoniy ma'nosiga ham ta'sir etishi ko'rsatilgan.

**Kalit so'zlar.** shaxs, sotsiolingvistik, fyeministik, sotsial, gender, psixolingvistik, aspekt, jamiyat

**Аннотация**. В данной стате показано, что во вцех лексических единисах ведущее место занимает значение выражения человека в родовом признаке, что сосиалное положение и отношения человека тесно связаны с различными факторами, и эта ситуасия также влияет на языковое значение лексических единис, выражающих сосиалные особенности человека.

**Ключевые слова:** личност, сосиолингвистический, фенимистский, сосиалный, гендер, психолингвистический, аспект, общество

**Annotation:** In this article, it is shown that in all lexical units, the meaning of expressing a person in terms of gender occupies a leading position, that a person's social status and relationships are closely related to various factors, and this situation also affects the linguistic meaning of lexical units expressing the social characteristics of a person.

**Key words.** personality, sociolinguistic, feminist, social, gender, psycholinguistic, aspect, society.

Shaxs sotsial belgisini ifodalovchi leksik birliklar sirasida gender, ya'ni jins nuqtai nazaridan tavsiflovchi so'zlar ham o'zbek tilining leksikasida o'ziga xos ma'no va vazifasi, lisoniy-ijtimoiy xususiyatlari bilan alohida ahamiyat kasb etadi. Ma'lumki, gender bir vaqtning o'zida shaxsning ijtimoiy-madaniy shartlashgan erkaklik va ayollik xususiyatlarini o'zlashtirish jarayoni hamda natijasini ifodalovchi tushuncha sifatida talqin etiladi. Shunga ko'ra, gender deganda jinsning ijtimoiy-madaniy aspektini ifodalovchi tushunchani nazarda tutish maqsadga muvofiq.